# «НАСЕЛЕННЫЕ ПУНКТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН: ИЛЛЮСТРИРОВАННАЯ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ» ФӘННИ-ПОПУЛЯР БЕЛЕШМӘЛЕГЕН ТӘРҖЕМӘ ИТҮГӘ НИСБӘТЛЕ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҺӘМ ТРАНСЛИТЕРАЦИЯ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Каюмова Г.И.***, *филология фәннәре кандидаты,*
***Бадрутдинова Ф.Р.***

# LEXICAL-SEMANTIC AND TRANSLITERATION FEATURES OF THE TRANSLATION OF THE SCIENTIFIC-POPULAR REFERENCE BOOK «SETTLEMENTS OF THE REPUBLIC OF TATARSTAN: ILLUSTRATED ENCYCLOPEDIA»

***Kayumova G.I., Badrutdinova F.R.***

Тел – һәр халыкның, һәр милләтнең үзара аралашу-аңлашу коралы, милли-рухи кыйммәтләр белән алмашу чарасы, милли-этник үзенчәлекләргә бай гореф-гадәтләрне, традицияләрне саклап тотучы хәзинә. Бер милләтнең әдәби-мәдәни мирасын икенче бер милләткә җиткерү тәрҗемә аркылы тормышка ашырыла. Бу уңайдан К. Фәтхуллова сүзләре игътибарга лаек: «Тәрҗемә ике телне – оригинал теле белән тәрҗемә телен генә үзара бәйләп калмый, ул төрле милләтләрне, төрле мәдәни катламнарны, төрле тарихи үсеш чорларын, үткән белән хәзергене берләштерә. Ул идеяне тудырган һәм аны кабул иткән мәдәниятләрнең икесен берьюлы колачлый»[1]. Тәрҗемә мәсьәләләре, бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү үзенчәлекләре турында В.В. Виноградов, В.Н. Комиссаров, Я.И. Рецкер, А.А. Смирнов, Л.Н. Соболев, Н.И. Фельдман, А.В. Федоров, В.Е. Шор, Е.Г. Эткинд, Г.Х. Алпаров, Ә.М. Ахунҗанов, Х.Р. Курбатов, К.С. Миңлебаев, Ф.С. Сафиуллина, С. Фәйзуллин, Р.А. Юсупов, яшь галимнәрдән Э.Н. Денмөхәммәтова, З.Н. Кириллова, Г.Р. Мөгътәсимова, К.С. Фәтхуллова, Г.Р. Чумарина һ.б.ның хезмәтләрендә этрафлы яктыртылган.

«Тәрҗемәченең бурычы – оригиналның эчтәлеген, авторның фикерләрен, стилен икенче телгә мөмкин кадәр тулы, төгәл итеп күчерү»[2]. Бу – тәрҗемә эшендә аеруча мөһим күренешләрнең берсе. Тәрҗемәченең, «иҗат ирееге» төшенчәсен ялгыш аңлап яисә махсус рәвештә, оригинал (чыганак) текстын үзе теләгәнчә үзгәртү хокукы юк. Теге яки бу текстны тәрҗемә иткәндә мәгънәгә һәм автор стиленә

зыян килергә тиеш түгел. Һәртөрле тәрҗемә ике тел белән эшләүне, ике тел арасында тәңгәллекләр табуны күздә тота. «Ике тел сүзләре арасында тәңгәллекләр табу – иҗади, катлаулы эш, һәм аны дөрес, уңышлы хәл итү өчен, үзара мөнәсәбәттәге телләрне, аларның лексик-семантик системалары нисбәтенең кануннарын, ике телнең дә сүзләре арасындагы бертөрле, охшаш якларны һәм специфик үзенчәлекләрне белү әһәмиятле»[3]. Әлеге мәкаләдә тарих, административ-территориаль бүленеш, сәнәгать, авыл хуҗалыгы, мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, табигый байлыклар, археологик һәм тарихи-мәдәни истәлекләр белән бәйле фәнни материалларны, шулай ук Татарстан Республикасының муниципаль районнарында һәм торак пунктларында туган күренекле шәхесләр турындагы мәгълүматларны туплаган «Населенные пункты Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия» («Татарстан Республикасы торак пунктлары: иллюстрацияле энциклопедия») исемле фәнни-популяр белешмәлекне[4] тәрҗемә иткәндә күзәтелгән лексик-семантик (семантика дигәндә сүзнең мәгънәсе күздә тотыла) үзенчәлекләрнең кайберләренә тукталып үтәрбез. Шул уңайдан «транслитерация» төшенчәсен дә аңлатып китү урынлы булыр. В.Н. Комиссаров сүзләре белән әйтсәк, «транслитерация – оригинал телендәге лексик берәмлекне тәрҗемә теленең хәрефләре ярдәмендә бирү»[5]. Әлеге үзгәртеп язуның төп бурычы – оригинал текстындагы мәгънәне саклау һәм төгәл җиткерү.

«Телгә өйрәтү һәм телне өйрәнү, тәрҗемә эше башкару өчен, һичшиксез, сүзлекләр кирәк, шунлыктан икетелле яисә күптелле тәрҗемәи лексикографик хезмәтләр теләсә кайсы телнең иң мөһим хәзинәләреннән берсе булып торалар. Татар теле дә мондый сүзлекләргә бай»[6]. Тәрҗемә ителәсе текстның мәгълүмати даирәсенә нисбәтле аерым тармакларга караган сүзлекләр, терминологик сүзлекләр белән дә эш итәргә туры килә. Шулай да бер телдән икенче телгә, аерым алганда, рус теленнән татар теленә тәрҗемә иткәндә, сүзлекләрдә теркәлгән билгеле, гомумкабул ителгән эквивалентлар белән генә эш итәргә ярамаганлыгы мәгълүм, тәрҗемә ителәсе сүзнең лексик-семантик үзенчәлекләрен исәпкә алу мөһим. Мәсәлән, «…занимает крутой правобережный склон долины реки Устье, сложенный известковыми породами» җөмләсендә «сложенный» сүзен сүзлектә бирелгән тәрҗемәләре (килеп чыккан, урнашкан, җитлеккән, өлгергән, формалашкан) белән тәрҗемә итеп булмый, мәгънәләре туры килми. Шуңа күрә, оригинал телендәге сүзнең мәгънәсеннән чыгып, тәрҗемәне түбәндәгечә бирү уңышлырак һәм дөрес булыр: «…Устье елгасының известьле токымнардан торучы уңъяк текә сөзәклеге били; серые лесные почвы представлены светло-серыми, серыми и темно-серыми подтипами – соры урман туфраклары аксыл-соры, соры һәм караңгы-соры астиплардан гыйбарәт; светло-серые и серые лесные пестроцветные почвы развиты на юго-западе района

на возвышенных местах выходов известняков, мергелей, пермских глин – аксыл-соры һәм соры чуар төстәге туфраклар районның көньяк-көнбатышында известьташлар, мергельләр, Пермь чоры балчыклары чыккан калкулыклы урыннарда таралганнар; коренной берег – төп яр һ.б.»

Тәрҗемә эшендә еш кына сүзлекләрдә бирелмәгән, аларда исәпкә алынмаган тәрҗемә сүзләре белән дә эш итәргә туры килә, мондый очракта тәрҗемә оригинал контекстыннан чыгып, ягъни аерым җөмләгә, абзацка яки бүлеккә бәйле рәвештә хәл ителә. Түбәндәге мисалларга игътибар итик: «Склоны ложбин и плоские гряды между ложбинами с дерново-подзолистыми почвами заняты темнохвойными лесами, сложенными елью и пихтой – Уйсулык сөзәклекләре һәм алар арасындагы кәсле-көлсу туфраклы яссы сыртларны чыршы һәм ак чыршы катнаш караңгы ылыслы урманнар били; рукотворный лес – утыртылма урман; сосудистые растения – көпшәле үсемлекләр; неглубокие разветвленные логи – тирән булмаган чокырлар белән бүлгәләнгән».

Кайвакыт оригиналның бер сүзе ике яки берничә сүз белән һәм, киресенчә, ике яки берничә сүзе бер сүз белән дә тәрҗемә ителергә мөмкин. Югарыдагы тезмәдә үк шушы очракның берсенә юлыгабыз: бер сүздән торган неглубокий сүзе татарчага, күргәнебезчә, «тирән булмаган» дип ике сүз белән тәрҗемә ителә; шушы очракка тагын бер мисал: «валовой азот в почве – туфракта азотның гомуми тәшкиләте…». Торак пунктның табигате белән бәйле «темнохвойно-широколиственные с липой и кленом» тибындагы рус тезмәсен татарчага тәрҗемә иткәндә «с» предлогы татар җөмләсендә «катнаш» сүзе белән бирелә: «юкә һәм өрәңге катнаш караңгы ылыслы киң яфраклы…». Тәрҗемәне камил, матур яңгырашлы итү максатыннан чыганак телендә еш кабатланган сүзләрне тәрҗемә телендә төрле синонимнары белән бирү, мәгънәсеннән чыгып төшереп калдыру да каралган, тәрҗемә процессында оригиналдагы кайбер сүзләрне махсус төшерү дә кирәк булырга мөмкин.

Гомумкабул ителгән «терминнарны, ай, көн, хайван исемнәрен, кайбер туганлык, эш кораллары атамаларын, зат алмашлыкларын» бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә «даими тәңгәллек» төшенчәсе турында сүз алып барырга мөмкин. Болар мәгънә һәм стиль ягыннан һәрвакыт туры килә торган сүзләр һәм тезмәләр: «сугышчан Дан ордены, Хәрби-Диңгез флоты, гыйнвар, февраль, март, дүшәмбе, сишәмбе, аю, төлке, бүре, винтовка, балта, пычкы, мин, син, ул һ.б.». Тәрҗемә эшендә калька күренешләргә дә юлыгырга мөмкин. Торак пунктларның табигатенә бәйле рәвештә еш кына «живая природа» төшенчәсе очрый. «Тере табигать» дип язу – калька күренеше, табигать болай да тере, шуңа күрә аны «табигать» дип кенә бирәбез (Р. Юсупов).

«Кайбер тәрҗемәчеләр, – дип яза Р. Юсупов, – телдәге рус алынмаларын киметү нияте белән булса кирәк, аларны һәрвакыт татарның

үз сүзләре белән генә бирү өчен кирәгеннән артык тырышалар, нәтиҗәдә яңа татарча терминнар барлык очракларда да тиешле мәгънәне белдерә алмыйлар»[7]. Бу күренешләргә галим «күкрәк билгесе, очкыч, хисапчы, спорт остасы, Дәүләт бүләге иясе» һәм башка сүз һәм сүзтезмәләрне мисал итеп китерә. Күптомлы Татар энциклопедиясе текстларын тәрҗемә иткәндә сүзләрне саф татарча итеп бирү омтылышы безнең тәрҗемәчеләр һәм мөхәррирләр арасында да күзәтелде. Татарстан Республикасы торак пунктлары текстларын тәрҗемә иткәндә дә аларның кайберләре (күкрәк билгесе, спорт остасы, хисапчы һ.б.) сакланды. Татар энциклопедиясенә кергән мәкаләләрне тәрҗемә иткәндә очраган «лауреат Государственной премии» тезмәсен «Дәүләт бүләге иясе» дип биргән булсак, Торак пунктларга багышланган мәкаләләрдә, лексик-семантик хилафлыктан саклану өчен, «Дәүләт бүләге лауреаты» дип бирү кулай күрелде. Бу уңайдан Р. Юсупов кисәтүе урынлы булыр: «Дәүләт бүләге иясе» дип «татарчалаштырып» атау үзен акламый: премия ул бүләк түгел, «лауреат» та «ия» түгел; «премия лауреаты» – тезмә интернациональ термин»[8]. «Термин – логик формалашкан төшенчәне барлык билгеләре белән төгәл итеп атап күрсәтүче сүз һәм сүзтезмә»[9] буларак, тәрҗемә вакытында аерым игътибар һәм төгәллек таләп итә. Район һәм район үзәкләре турындагы текстларны тәрҗемә иткән вакытта, аларның мәдәнияте, табигате, күренекле шәхесләре белән бәйле рәвештә, күптөрле терминнар белән эш итәргә туры килә.

Мәгълүм булганча, «оригинал теленең һәр сүзе тәрҗемә телендә аерым сүз белән бирелергә тиеш дигән ялгыш фикер еш кына татар теленең лексик-семантик нормаларын бозуга китерә»[10]. Андый очракта, татар телендәге рус алынмаларын җентекле өйрәнгән күренекле галим Ә.М. Ахунҗанов[11] фикерләрен раслап, «туган телнең үзендә чит тел сүзен бер сүз белән генә белдерерлек чара булмаганда», рус теленнән татар теленә кереп ныгып калган, актив кулланылыштагы үз сүзләрен калдыру яхшырак дигән фикергә киләбез. Безнең тәрҗемәдә иң еш очрый торганнары түбәндәгеләр: «состав (составында), профиль (күппрофильле), тенденция, контекст, идеология, профессиональ (җырчы), процент, премия, лауреат, кооператив, предприятие, контексттан чыгып, күп очракта зыялылар урынына интеллигенция» сүзе еш кулланыла һ.б. Интернет челтәрендә «Знак почета» орденының «Хөрмәт билгесе» рәвешендәге тәрҗемәсенә юлыгырга мөмкин: татар телендә рәсми рәвештә «Почет билгесе» буларак кабул ителгән орден исеменең шул рәвешле ирекле тәрҗемәдә бирелүен зур хата дип санарга кирәк. Бу очракта «почет» төшенчәсенең мәгънәсе киңрәк һәм аны шулай калдыру дөрес.

Безнең тәрҗемәдә Р. Юсупов өнәп бетермәгән «гаммәви, хөкем, хөкемдар, мәхкәмә, тәхәллүс, көллият, фәрман, товарлыклысөтчелек» сүзләре дә актив кулланыла. Мәсәлән, «гаммәви акцио-

нерлык җәмгыяте»; «фәрман» сүзе тарихи текстларга мөнәсәбәтле файдаланыла, хокук белгече дибез, әмма профессиясен күздә тотканда, «юрист» төшенчәсен кулланабыз; борынгы әдипләрнең псевдонимнары турында сүз алып барганда «тәхәллүс» сүзен куллануны урынлы дип таптык. Галим билгеләп үткәнчә, соңгы берничә елда матбугатта рус алынмаларының һәм халыкара сүзләрнең чыганак телендәгечә әйтелеш һәм язылыш нормаларын үзгәртергә омтылу, ягъни «татарчалаштыру» тенденциясе хөкем сөрә, без дә берара, шул тенденциягә ияреп, крестьян сүзен «крәстиян» дип, секретарьне «сәркатип» дип яза башлаган идек.

Торак пунктлар турындагы текстларны тәрҗемә иткәндә еш кына ялгызлык исемнәр белән дә эш итәргә туры килә. Боларга торак пункт, учреждение, оешма, завод-фабрика, газета-журнал исемнәре, кеше исем-фамилияләре һ.б. керә. Авылларны һәм поселокларны үз эченә алган торак пунктларның татарча бирелеше Юстиция министрлыгы тарафыннан эшләнгән. Күпчелек торак пункт исемнәре нинди дә булса мәгънә белдерүләреннән чыгып тәрҗемә ителгән: Верхний Берсут – Югары Кыярлы авылы (Мамадыш районы), Теплое Болото – Түбән Әрнәш (Мамадыш районы), Кривоозерки – Кәкрекүл авылы (Аксубай районы), Новое Демкино – Яңа Дума авылы (Аксубай) һ.б. Исемгә салынган мәгънә инде онытылган очракта, топонимика исемнәре тәрҗемә ителмәскә дә мөмкин, мәсәлән: Гришкино, Красная Горка, Кулуш-Пустошь, Соколка, Грахань, Гурьевка авыллары (Мамадыш районы); Байкал, Каратай, Наласа, Пионер, Чиканас (Арча районы). Торак пункт исемнәренең зур күпчелеге оригинал теленнән (безнең очракта рус теленнән) татар теленә татар хәрефләре белән транслитерацияләнә: Мирзям – Мирҗәм, Пшенгер – Пөшәңгәр, Хасаншаих – Хәсәншәех, Абзябар – Әбҗәбәр авыллары (барысы да – Арча районында), Масады – Мәсәде авылы (Актаныш районы). Ике сүздән торган авыл исемнәренең сыйфат белән бирелгән беренче өлеше тәрҗемә ителеп, исем белән белдерелгән икенче өлеше транслитерация юлы белән күчерелгән очраклар күп: Средние Верези – Урта Бирәзә, Новый Кинер – Яңа Кенәр, Малая Атня – Кече Әтнә авыллары (барысы да Арча районында), шулай ук беренче өлеше тәрҗемә ителеп, икенче өлеше оригинал телендәгечә калдырылган торак пункт исемнәре дә бар: Большой Арташ – Олы Арташ, Старый Завод – Иске Завод (икесе дә – Мамадыш районында), Новая Варваринка – Яңа Варваринка, Новое Елхово – Яңа Елхово (икесе дә – Лениногорск районында) һ.б. Без тәрҗемәчеләр, мөхәррирләр, кайбер авылларның тәрҗемәләре белән килешеп бетмәсәк тә, һич каршылыксыз шушы чыганакка таянырга мәҗбүрбез.

Ансамбльләр, җыр һәм бию коллективлары, театрларның исемнәре, шулай ук газета-журнал исемнәре тәрҗемә текстында оригиналдагыча бирелә: «Сударушка» рус фольклор ансамбле (Мамадыш районы,

«Мамадыш» совхозы поселогы), «Марий памаш» мари халык фольклор ансамбле (Мамадыш районы, Гришкино авылы), «Русская песня» вокаль ансамбле (Арча шәһәре), «Шишор» мари фольклор ансамбле (Арча шәһәре), «Калинушка» вокаль ансамбле (Баулы шәһәре), «Сударушка» (Баулы шәһәре, Кырымсарай авылы), «Тарават» (Баулы шәһәре, Потапово-Томбарлы авылы), «Зярдон» (Баулы шәһәре, Покровский Урустамак авылы) фольклор ансамбльләре, «Мирас» фольклор коллективы, «Тургай» бию коллективы (Ютазы районы, Бәйрәкә авылы), «Сеспель» халык театры (Баулы шәһәре, Потапово-Томбарлы авылы); «Советская Татария» газетасы, «Мамадыш тавышы» газетасы (газета «Мамадыш тавышы»). Рус хәрефләре белән татарча яңгыраштa бирелгән ялгызлык исемнәр татар теленә татар хәрефләре белән транслитерацияләнә: ансамбль песни и танца «Нократ бизэклэре» – «Нократ бизәкләре» җыр һәм бию ансамбле (Мамадыш районы), Детский театр кукол «Сэлэт» – «Сәләт» балалар курчак театры (Мамадыш районы), кряшенский фольклорный коллектив «Жингэчэйлэр» – «Җиңгәчәйләр» керәшен фольклор коллективы (Мамадыш районы, Дүсмәт авылы), родник «Изгелэр чишмэсе» – «Изгеләр чишмәсе» (Мамадыш районы, Иске Комазан авылы).

Фразеологик сүзтезмәләр белән бирелгән җәмгыять, учреждение, оешма, уку йортлары татарчага тәрҗемә ителә: «общество с ограниченной ответственностью (ООО) – җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять (ҖЧҖ), закрытое акционерное общество (ЗАО) – ябык акционерлык җәмгыяте (ЯАҖ), крестьянское (фермерское) хозяйство (КФХ) – крестьян-фермер хуҗалыгы, сельскохозяйственный производственный кооператив (СХПК) – авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы һ.б.» Шушы җәмгыять, учреждение, оешмаларның исемнәре тәрҗемәдә, нигездә, оригинал телендәгечә калдырыла: «Продовольственная программа» агросәнәгать комплексы» ҖЧҖ (Мамадыш районы, Көек-Ерыкса авылы), «Татгазстрой» ЯАҖ (Арча районы, Урта Бирәзә авылы), «Надежда» балалар һәм яшүсмерләр социаль приюты (Мамадыш районы, Красная Горка авылы), «Забота» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге (Мамадыш шәһәре). Рәсми документларда аларның татарча исемнәре дә кабул ителгән яки татар телендәге торак пункт исеме белән бәйле булган очракта, шулай ук кулланылыш даирәсе киңлегеннән һәм ешлыгыннан чыгып, татарчага тәрҗемә итәбез: «Азык-төлек корпорациясе» ҖЧҖнең Мамадыш филиалы, «Тәкәнеш» агросәнәгать комплексы» ҖЧҖ (Мамадыш районы, Урта Тәкәнеш авылы), «Мамадыш азык-төлек корпорациясе» ҖЧҖ, «Актаныш икмәк комбинаты» ҖЧҖ, «Актаныш басмаханәсе» фәнни-җитештерү предприятиесе» ҖЧҖ.

«Тәрҗемә мәсьәләләре» хезмәтендә Р. Юсупов: «Колхоз, совхоз исемнәре тәрҗемә ителми: «Путь Ильича колхозы», «Заря» совхозы»[12], – дип яза. «Населенные пункты Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия»

(«Татарстан Республикасы торак пунктлары: иллюстрацияле энциклопедия») хезмәтен тәрҗемә иткәндә, бу проблемага һәр авылда юлыгабыз: колхоз-совхоз, алардан барлыкка килгән күмәк предприятиеләр һ.б.ның исемнәрен бирүдә төрлелек бар, нигездә, күбесен русча калдырабыз: «Прикамский» колхозы (Мамадыш районы, Кулуш-Пустошь авылы), «Октябрьский» колхозы (Мамадыш районы, Омар авылы), «Омарский» совхозы (Мамадыш районы, Омар авылы), «Зеленогорский» колхозы (Мамадыш районы, Керәшен Пакшины авылы), «Красное знамя», «Дружба» колхозлары (Мамадыш районы, Гришкино авылы), «Путь к коммунизму» колхозы (Мамадыш районы, Рагозино авылы), «Прикамье» күмәк предприятиесе (Мамадыш районы, Рагозино авылы), «Рассвет» күмәк предприятиесе (Мамадыш районы, Шәмәк авылы). Авылда сан ягыннан татарлар күбрәк булган очракта, кайбер колхоз, совхоз исемнәрен тәрҗемә итәбез. Мәсәлән, Мамадышның Сәртек авылында авыл халкының зур күпчелеген татарлар тәшкил итә, шуны исәпкә алып, «13 годовщина Октября» колхозын «Октябрьнең 13 еллыгы» колхозы» дип татарча тәрҗемәдә бирәбез; Сикәнәс авылында халыкның зур күпчелеге – руслар, шул сәбәпле колхоз исемнәренә дә үзгәреш кертмибез: «Верный путь», «Ударник» колхозлары (колхоз исемнәренең куштырнакка алынган булуы аларны чыганак телендәгечә калдыруны аклый да), әмма татар текстында «Имени XXI партсъезда колхозы» дип язу асылда дөрес булмас иде, шул сәбәпле «XXI партсъезд исем. колхоз»; «колхоз имени Ворошилова – Ворошилов исем. колхоз» дип тәрҗемәсен бирәбез. «Мамадыш» совхозы поселогы» дип аталган торак пунктның, исеменнән чыгып, анда эшчәнлек алып баручы совхозны да «Мамадыш» совхозы (русчасы – совхоз «Мамадышский») рәвешендә бирүне дөрес булыр дип таптык. Кайбер татарча яңгырашлы колхоз-совхоз, җәмгыять исемнәре рус текстында русча транслитерациядә бирелгән булып, татар теленә шул килеш татар хәрефләре белән генә күчерелә: колхоз «Уныш» – «Уңыш» колхозы (Мамадыш районы, Тулбай авылы), колхоз «Тан» – «Таң» колхозы (Мамадыш районы, Иске Комазан авылы), ООО АПК «Таканыш» – «Тәкәнеш» агросәнәгать комплексы» ҖЧҖ (Мамадыш районы, Урта Тәкәнеш авылы). Кайбер ялгызлык исемнәрне бер телдән икенче телгә күчергәндә транслитерация һәм транскрипция (әйтелеш) саклана: колхоз «Алан» – «Алан» колхозы, коллективное предприятие «Игенче» – «Игенче» күмәк предприятиесе (Мамадыш районы, Урта Кирмән авылы). Русча язылган татар фамилияләрен һәм инициалларны татарчалаштырабыз: Л.А. Аухадеева – Л.А. Әүхәдиева, М.Г. Ахметзянов – М.Г. Әхмәтҗанов, К.А. Валиев – К.Ә. Вәлиев, А.М. Закирзянов – Ә.М. Закирҗанов һ.б. Кеше исем-фамилиясе белән аталган һәм хуҗасы татар булган теге яки бу крестьян-фермер хуҗалыгының исеме тәрҗемәдә татарча күрсәтелә һәм, күпчелек документлардан

чыгып, куштырнакларга алына: КФХ «Шакирзянова Д.Ф.» – «Шакирҗанов Д.Ф.» крестьян-фермер хуҗалыгы (Мамадыш районы, Урта Кирмән авылы), КФХ «Хасаншина Р.К.» – «Хәсәншин Р.К.» крестьян-фермер хуҗалыгы (Мамадыш районы, Югары Сон авылы).

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә ниндидер кытыршылыклар, кимчелекләр булуга карамастан, ике телдә дөнья күргән бай эчтәлекле «Татарстан Республикасы торак пунктлары: иллюстрацияле энциклопедия» хезмәте төрле милләт вәкилләрен берләштергән һәр торак пункт, аның тарихи, рухи-мәдәни, сәнәгый һәм башка казанышлары хакында рус һәм татар телләрендә системага салынган гомуми күзаллау булдыруга булышлык итә, фәннең төрле тармаклары буенча хезмәт куйган күренекле шәхесләрне барлау мөмкинлеге тудыра һәм милли-этник кыйммәтләрне яктырткан рухи мирас булып тора.

**Сведения об авторах:** Каюмова Гульия Ильдусовна, кандидат филологических наук, старший научный сотрудник Центра энциклопедистики Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: guliya.kayumova@yandex.ru; Бадрутдинова Фирая Равилевна, старший научный сотрудник Центра энциклопедистики Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ.

**Аннотация.** В статье на примере текстов энциклопедического справочника «Населенные пункты Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия» рассматриваются некоторые лексико-семантические и транслитерационные особенности перевода с текста оригинала (в данном случае с русского языка) на татарский язык. Исходя из тематического разнообразия исследуемого материала, авторам статьи пришлось поднять вопросы перевода понятий и терминов, относящихся к разным отраслям знаний.

**Ключевые слова:** Республика Татарстан, населенные пункты, промышленность, культура, природа, перевод, лексико-семантические особенности, транслитерация.

**Abstract.** The article examines some lexical-semantic and transliteration features of translation from the original text (in this case from Russian) into Tatar using the example of the texts of the encyclopedic reference book «Settlements of the Republic of Tatarstan: illustrated encyclopedia». Based on the thematic diversity of the research material, the authors of the article had to raise the issues of translation of concepts and terms related to different branches of knowledge.

**Key words:** The Republic of Tatarstan, settlements, industry, culture, nature, translation, lexical-semantic features, transliteration.

## ИСТОЧНИКИ И ЛИТЕРАТУРА

1 Фатхуллова К.С. Художественный текст как объект перевода // Төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате Шәрык һәм Гареб мәдәнияте контекстында: Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы (14–17 октябрь 2015 ел) / Р.Р. Җамалетдинов редакциясендә. – Казан: Отечество, 2015. – С. 539.

2 Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 10.

3 Шунда ук. – Б. 21.

4 Населенные пункты Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия: в 3 т. – Казань: Ин-т Татар. энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2018. – Т. 1. – 712 с.;

Населенные пункты Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия: в 3 т. – Казань: Ин-т Татар. энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2021. – Т. 2. – 988 с.

5 Комиссаров В.Н. Теория перевода (лингвистические аспекты): учеб. для ин-тов и фак. иностр. яз. – М.: Высш. шк., 1990. – С. 173.

6 Денмөхәммәтова Э.Н. Мәдәният һәм әдәбиятара бәйләнешләр булдыруда икетелле сүзлекләр // Төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате Шәрык һәм Гареб мәдәнияте контекстында: Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы (14–17 октябрь 2015 ел) / Р.Р. Җамалетдинов редакциясендә. – Казан: Отечество, 2015. – Б. 198.

7 Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 41.

8 Шунда ук. – Б. 42.

9 Кириллова З.Н. Икетеллелек шартларында фәнни әдәбиятны тәрҗемә итү // Төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате Шәрык һәм Гареб мәдәнияте контекстында: Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы (14–17 октябрь 2015 ел) / Р.Р. Җамалетдинов редакциясендә. – Казан: Отечество, 2015. – Б. 334.

10 Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм дөрес сөйләм мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – Б. 37.

11 Ахунзянов Э.М. Русские заимствования в татарском языке. – Казань: изд-во Казан. ун-та, 1968. – 367 с.

12 Юсупов Р.А. Тәрҗемә мәсәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Б. 44.